ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге составына керүче Соколка Урманчылыгы торак пунктында 2025 елга үзара салым кертү турында

№ 4 19.11.2024 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлегенең Соколка Урманчылыгы торак пунктында узган гражданнар җыены.

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Соколка авыл җирлеге Соколка Урманчылыгы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2025 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (сатып алу, су торбаларын алыштыру,торбаларны изоляцияләү яки тирәнәйтү, контракт буенча эш өчен түләү);
- урамнарны яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, махсус җиһазларны сатып алу һәм алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Соколка Урманчылыгы торак пунктындагы бистәләрендә юлларны кардан чистарту.

3. Әлеге карарны Соколка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Соколка авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе А.А. Гатиятуллин